Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Сугышлы авыл җирлеге
Сугышлы авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлыавыл җирлегенең Сугышлы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Сугышлыавыл җирлеге территориясендә Сугышлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән: I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1) Сугышлы авыл мәдәният йорты территориясендә яңа балалар бакчасы төзү һәм авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру ;

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә

– Сугышлы авылында су линияләренең өзеклекләрен бетерү эшләрен оештыру.

3) җирлек чикләрендә халыкны электр белән тәэмин итүне оештыру

- Сугышлы авылында (Үзәк ур., Гафиятуллин ур., Гагарин ур., Насос ур., Хәлиуллин ур.) урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

4) торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- 3 күрсәтмә билге алу,

– янгынга каршы хуҗалык инвентаре алу (5 көрәк, 5 метр,5 чиләк;

5) авыл җирлеге торак пункты чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру:

- Сугышлы авылы юлларын кардан чистарту ( Үзәк урамы, Гафиятуллин урамы, Гагарин ур., Насос ур., Хәлиуллин ур.);

- Сугышлы авылында (Үзәк ур., Гагарин ур., Хәлиуллин ур.) чокырларны ямау

«ӘЙЕ» «ЮК»

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 354 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 181 кеше. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

- җыенда катнашкан 177 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде.;

- «юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге составына керүче Сугышлы авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Сугышлы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән: I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

1) Сугышлы авыл мәдәният йорты территориясендә яңа балалар бакчасы төзү һәм авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру ;

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә

– Сугышлы авылында су линияләренең өзеклекләрен бетерү эшләрен оештыру.

3) җирлек чикләрендә халыкны электр белән тәэмин итүне оештыру

- Сугышлы авылында (Үзәк ур., Гафиятуллин ур., Гагарин ур., Насос ур., Хәлиуллин ур.) урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

4) торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- 3 күрсәтмә билге алу,

– янгынга каршы хуҗалык инвентаре алу (5 көрәк, 5 метр,5 чиләк;

5) авыл җирлеге торак пункты чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру:

- Сугышлы авылы юлларын кардан чистарту ( Үзәк урамы, Гафиятуллин урамы, Гагарин ур., Насос ур., Хәлиуллин ур.);

- Сугышлы авылында (Үзәк ур., Гагарин ур., Хәлиуллин ур.) чокырларны ямау

карарын кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

«Сугышлыавыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П. Зыятдинова